ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.12.2025 Олы Кайбыч ав. 583

2026 елга халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә
тарифларны раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2026 елга халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләре тарифларын билгеләргә һәм гамәлгә кертергә:

- социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны карап тоткан өчен, шулай ук гомуми җыелышта 2025 елга торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларда күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын һәм торак урыннар милекчеләрен сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме 1 нче кушымта нигезендә;
- муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү күләме (наем өчен база ставкасы) 2 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3.Түбәндәге карарларны гамәлдән чыккан дип санарга:

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 27 декабрендәге 489 номерлы «2025 елга халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифларны раслау турында»;
- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 29 сентябрендәге 392 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 27 декабрендәге 489 номерлы «2025 елга халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифларны раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында».

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч

муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025е. «26» 12
583 номерлы карарына
1 нче кушымта

Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны карап торткан өчен, шулай ук гомуми җыелышта 2025 елга торак урыннарын карап торткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларда күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын һәм торак урыннар милекчеләрен сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен

ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ

| т/б № | Түләү атамасы | Хезмәт үлчәү берәмлеге | Хезмәтне үлчәү берәмлегенә тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026елның 30 сентябренә кадәр | 2026 елның 1 октябреннән 2026 елның 31 декабренә кадәр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,10 | 1,25 |
| 2. | Торак бинага агымдагы ремонт | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 4,64 | 5,26 |
| 3. | Йорт эчендәге су үткәргеч-канализация челтәрләренә агымдагы ремонт һәм карап тоту | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,93 | 2,19 |
| 4. | Йорт эчендәге инженерлык канализация челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,06 | 1,20 |
| 5. | Электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,62 | 1,84 |
| 6. | Подъезд газүткәргечләре эчендә тышкы фасадка техник хезмәт күрсәтү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,72 | 0,82 |
| 7. | Газ белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,57 | 1,78 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8. | Җилләтү каналларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,13 | 1,28 |
| 9. | Төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 2,00 | 2,27 |
| 10. | Йорт яны территориясен җыештыру | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 3,90 | 4,42 |
| 11. | Йорт яны территориясен карап тору | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 5,34 | 6,06 |
| 12. | Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 8,60 | 9,75 |
| 13. | Дератизация | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 1,08 | 1,22 |
| 14. | Контейнер мәйданчыкларын карап тоту | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,90 | 1,02 |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 е. «26» 12
583 номерлы карарына
2 нче кушымта

Муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен база ставкасы)

ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ

| Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтү үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтү берәмлеге өчен нигез ставкасы (сумнарда), 2025 елга |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Наем буенча база ставкасы | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 02 февралендәге 56/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннардан файдалануга (наем өчен түләүгә) түләү күләмен исәпләү методикасы нигезендә |